

Азин Нуриәхмәт Хаҗи улы 1939 елның 10 нчы октябрендә Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туган. Сугыш башлангач әтисен сугышка алалар. Авыр сугыш елларында әтисе сугышта вафат була.Әнисе Рәхимә 5 бала белән тол кала.Хаҗи улы Нуриәхмәт Бәзәкә авылы мәктәбендә 4 сыйныфка хәтле белем ала,авыр еллар булганга ул укуны ташлап 14 яшендә колхозда эшли башлый.1953 елны көтүче булып эшли.1969 елны колхозда трактористлар курсын бетереп тракторда эшли башлый.Язын тракторда,көзен комбайнда эшләп югары уңышларга ирешә. Күп кенә район,Республика дәүләт бүләкләренә лаек була.Дәүләтнең иң югары бүләге орденга лаек була.Авыл советы депутаты булып та сайлана.61 ел “Кама” колхозында хезмәт итә.

Тормыш иптәше Римма белән 56 ел бергә гомер итәләр. Биш бала үстереп олы тормыш юлына бастыралар.Хәзерге вакытта аларның җиде оныклары, өч оныкчыклары бар.

Лаеклы ялга чыккач та колхозны ташламый колхозда мал карауычы булып, 75 яше тулганчы эшли. Авыл халкына да һәрвакыт та ярдәм итә.Шуңа күрә аны авыл халкы хөрмәт итә.